СОВЕТ НОВОМЕЛЬКЕНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЯНА МӘЛКӘН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

телефон: (85555)2-37-25. E-mailNmelMnz@tatar.ru

# КАРАР

№2 28.11.2024

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Яңа Мәлкән авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Яңа Мәлкән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмә турында» 15.04.2019 № 2 карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы №25-ФЗ Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында 25.06.2013 елгы №50-ТРЗ Татарстан Республикасы кодексы нигезендә,«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «Федераль законның 79 статьясына үзгәрешләр кертү турында»23.03.2024 N 54-ФЗ Федераль законы һәм "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" Федераль Законның 28.1 маддәсе,«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында»08.08.2024 елгы №232-ФЗ Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Яңа Мәлкән авыл җирлеге Советы

КАРАР ЧЫГАРА:

1.Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Яңа Мәлкән авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Яңа Мәлкән авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмә турында» 15.04.2019 № 2 карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 16 өлешнең 8 пунктында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга.;

1.2. 28 өлешнең 2 пунктында", муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе" сүзләрен һәм", муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппараты " сүзләрен төшереп калдырырга.;

1.3. 12 өлешнең 2 пунктында "муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләренең," сүзләрен төшереп калдырырга;

1.4. 15 бүлекнең 1 пунктында", муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга.;

1.5. 36 бүлекнең 2 пунктында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясен» сүзләрен төшереп калдырырга.;

1.6. 36 бүлекнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Муниципаль хезмәткәр Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән җирле үзидарә органы бетерелгәндә,аның шәхси эше саклауга ябылган җирле үзидарә органы функцияләре тапшырылган җирле үзидарә органына яисә аның хокукый варисына тапшырыла.».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Яңа Мәлкән авыл җирлеге башлыгы Нәҗметдинов З.И.